Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFØNYN

УНИВЕРСИТЕТ

12+

№37
(130)

25 декабрь
2014 ел



Влад Михневский фотосы

# Хуш киләсең, Яңа ел!

Тылсымлы Яңа ел төнендә һәркайсыбыз хыял диңгезендә йөзә, барлык теләкләрнең дә үтәләсенә ышана. Яңа ел Сезнең өчен ышаныч-өметләрнең аклану, уй-хыялларның чынга ашу елы булсын!
Күтәренке кәеф һәм күңел көрлеге һәрвакыт изге эшләргә өндәп торсын!
Сезгә һәм якыннарыгызга бәхет, исәнлек-саулык, иминлек һәм мул тормыш телибез!

Еллык нәтиҗә

# Безнең университет, уртак җиңүләр һәм якты киләчәк!

Казан университетының 210 яшьлек юбилее узган һәм хәзерге җиңүләргә яңа күзлектән карарга һәм киләсе елга яхшылап әзерләнергә мөмкинлек бирде. Яңа елга керер алдыннан, 2014нче ел бүләк иткән иң мөһим вакыйгаларга тукталасы килә.

Алинә САДЫЙКОВА















Кышкы яллардан соң, кайчак студентларга имтиханнарга әзерләнергә, уку процессына кереп китәргә авыр була. Шуңадыр инде, алар **Студентлар көнен** 25 гыйнварда үткәрде. Бәйрәм концертында студентлар җырбиюләрен, театраль сәхнә, һ.б. чыгышларын тәкъдим итте. Шул ук көнне ТРның **Махсус дәүләт стипендиясенә лаек булган студентларны һәм аспирантларны бүләкләү** булды. Быел аны Татарстанның 80 студенты һәм аспиранты алды. Шуларның 20се Казан федераль университетында укый.

Шул ук көнне уздырылган ТРның **«Ел студенты» премиясен** тапшыру тантанасында уку йортыбызга тиңнәр булмады дияргә мөмкин. КФУ студентлары, күп кенә номинацияләрдә җиңү яулап, белем йортыбызга тагын бер зур дәрәҗәле исем алу мөмкинлеге бирде. Казан федераль университеты **«Ел вузы»**, студентыбыз Илдар Хөжжәтов исә **«Ел студенты»** булды. Бу безнең зур, уртак җиңүебез.

Казан университеты студентлары, ел дәвамында, укудан тыш, яшьтәшләре, башка вуз студентлары белән аралашырга да вакыт таба. Мартның күңелләргә матурлык һәм сафлык өсти торган гүзәл бер көнендә Казан студентлары һәм чит илләрдән килгән студентлар «Идел» Яшьләр үзәгенә **«Татарстанның мәдәни мозаикасы» фестиваленә** җыелды. Ул республикабыз яшьләре арасында мәдәниятара диалог атмосферасын үстерү һәм саклау максатыннан оештырылды. Монда һәр студентка үз милләтен күрсәтергә, тәкъдим итәргә мөмкинлек тудырылган иде.

2014нче елның тагын бер сөенечле вакыйгасы – Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында халкыбызның төрле катлам вәкилләре өчен ачылып бушлай **татар теле курслары** эшли башлады. Укыту эшләре тиешле югарылыкта башкарылганга, укучылар бик канәгать калган һәм аларның күбесе татар телен өйрәнүләрен икенче елда да дәвам итәчәк.

КФУ студентлары – сәламәт студентлар! Апрель башында ел саен үткәрелә торган **«Сәламәтлек көне»** акциясе моңа ачык мисал булып тора. Аның кысаларында студентлар өчен сәламәтләндерү практикалары һәм техникалары буенча мастерклассларда катнашу, дәвалаупедагогик скрининг процедурасын үтү, төрле тип бәйләнеш мәсьәләләре буенча белгеч һәм психологка мөрәҗәгать итү мөмкинлекләре тудырылды.

Язның икенче ае иҗат сөючеләр өчен дә күңелле вакыйгалар алып килде.

21 апрельдә **«Илһам» яшь язучылар бәйгесенең йомгаклау кичәсе** һәм җиңүчеләрне премияләр белән бүләкләү тантанасы узды. Бәйгедә 722 иҗади эш белән барысы 715 яшь язучы катнашты.

Уку йортыбызга быел яз бик иртә килеп, студентларны тиз «уятты». Март башында старт алган **«Студентлар язы»** фестивале 23 апрель көнне финишка килеп җитте. Уникс концертлар залында иң матур җырлардан, иң дәртле биюләрдән, иң якты чыгышлардан гына торган галаконцерт узды. Эндрю Ллойд Эбберның «Призрак оперы» мюзиклына нигезләнеп әзерләнгән фестиваль бүгенге көн студентларының ни дәрәҗәдә актив, креатив, сәнгатькә гашыйк булуларын тагын бер кат дәлилләде.

Апрель ае – туган тел өчен вакыйгаларга мул ай. 27-30 апрельләрдә Казанда **II халыкара татар теле һәм әдәбияты олимпиадасы** узырылды. Иң яхшы нәтиҗәләр күрсәткән 300 катнашучы, белемнәрен сынау өчен, башкалабызга җыелды.

16 майда Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында **РФнең Мәгариф һәм фән министры урынбасары Александр Климов** булды. Ул телгә өйрәтүнең торышы, бу өлкәдәге яңа төр методикалар һәм инновацион проектлар белән танышу өчен килде.

17 майда Уникс концертлар залында бик кызу иде, чөнки биредә **«Дөнья мәрҗәне – 2014» V Халыкара матурлык һәм сәләт конкурсы** булды. Төрле илләрдән килгән кызлар, өч төрле сынау аша үтеп, үзләрен күрсәтте. Нәтиҗәдә Мисс-Дөнья мәрҗәне исеменә Үзбәкстаннан килгән студент Надира Корбанова лаек булды.

20 май көнне төп бинада **«КФУның иң яхшы академик төркеме» конкурсы** җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды. Әмма, җиңүгә ирешкәнче, катнашучыларга җитди сынаулар аша үтәргә туры килде.

19 май көнне республика Журналистлары арасында **XVII «Бәллүр каләм – Хрустальное перо» конкурсының йомгаклау тантанасы** узды. Конкурстан безнең редакция дә читтә калмады. «Дарелфөнүн» газетасы «Татарстан Республикасында чыга торган корпоратив һәм махсуслашкан гаммәви мәгълүмат чаралары» номинациясендә җиңүгә лаек булды.

26 май көнне студентларның иң мөһим бәйрәмнәренең берсе – **«Студентлар язы – 2014»** Республика студентлар иҗаты фестиваленең Галаконцерты булды. Анда КФУ Гран-прига лаек дип табылды. Шул ук көнне КФУ студентлары арасында **«Иң яхшы фәнни эш»** конкурсына да нәтиҗә ясалды. Быел 192 студентның эше бәйгенең икенче турына үткән. Шуларның 134е – социогуманитар фәннәр, калган 58 эш табигый фәннәр юнәлешенә багышланган иде.

Казан университетының **Хор капелласы** 9-19 июль көннәрендә Ригада узган Бөтендөнья хор уеннарында (World Choir Games) җиңү яулап, туган уку йортына алтын диплом белән кайтты. Әлеге уеннар – ике елга бер тапкыр Җир шарының төрле континентларында үткәрелә торган чара. Быел анда 27000гә якын җырчы көч сынашты.

Яңа уку елын студентлар иҗади рәвештә җибәрде. 15 сентябрь көнне **«Студ'звезда – 2014» яшьләр иҗади проектының** финалы булды. Сайлап алу туры нәтиҗәләре буенча финалга З.Вильданова (КФУ), Р.Мортазин (КАИ – А.Н.Туполев ис. КМТТУ), А.Әхмәтгәрәева (И.В.Әхәдиев ис. КМК) чыкты. Җиңүне университетыбызның 4 курс студенты З.Вильданова яулады.

Бу айда үзенчәлекле вакыйгалар байтак булды. Мисал өчен, 21 сентябрьдә танылган рус галиме, Казан университетының Астрономия обсерваториясенә нигез салучы В.П.Энгельгардтны яңадан күмү йоласы булды. Чарада КФУ ректоры И.Гафуров, ТРның беренче Президенты М.Шәймиев, РФнең Финанслар министры А.Лавров һ.б. дәрәҗәле кешеләр катнашты. Әлеге вакыйга И.Гафуров инициативасы белән, КФУ галимнәре ярдәмендә башкарылды.

Фән өлкәсендәге яңалыкларга күз салсак, 7 октябрьдә Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбендә узган **CisCo инновацияләр үзәген ачу тантанасын** билгеләргә кирәк. Чарада ТР Президенты Р.Миңнеханов катнашты. Бу үзәк – Россиядә югары уку йорты базасында ачылган мондый дәрәҗәдәге беренче проект.

Җир астында ниләр бар? Бу сорау шулай ук Россиянең 72 төбәге һәм 22 чит илдән 950ләп җир асты серләрен өйрәнүче галимне дә борчыды. Аларның Казанда үткәрелә торган **IV (XX) Бөтенроссия археология съездына** (20-25 октябрь) җыелуларының сәбәбе дә нәкъ шунда.

Ноябрь аенда **«Телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» III халыкара Фәнни-гамәли форум** да бик уңышлы гына узды. 3 көн буе дәвам иткән форум кысаларында барлыгы 2 пленар утырыш, 19 секция утырышы, 6 түгәрәк өстәл, 4 мастеркласс уздырылды. Анда туган тел һәм мәдәниятләрне үстерү перспективалары, аларны саклап калу һәм алга җибәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең ярдәме һ.б. кызык темаларга фикер алыштылар.

Студентлар өчен иң абруйлы, иң дәрәҗәле бәйге – ул **«Ел студенты»**дыр, мөгаен. «Ел студенты-2014» Россия милли премиясе илебез күләмендә тәүге мәртәбә «Студентлар Россиясе» Бөтенроссия форумы кысаларында Казанда уздырылды. Конкурста Россиянең 45 төбәгеннән 400гә якын студент катнашырга теләк белдергән. Иң алдынгы студентлар барлыгы 9 профильле номинациядә һәм гранпри өчен көч сынашты. КФУ студенты Илһам Галиуллинга «Ел ачышы» номинациясендә тиңнәр булмады.

24 ноябрьдә иҗат утында янучыларянәдәнбермәйдәнда җыелды. Бу көнне **«Илһамлы каләм»** һәм **«Шигъри сабантуй»** бәйгеләренең йомгаклау тантанасы булды. «Шигъри сабантуй»га шигърият буенча эшләр килсә, «Илһамлы каләм»гә проза, драматургия һәм публицистика буенча эшләр кабул ителде. Чарада бәйгенең икенче турына үткән укучылар катнашты.

Университетыбызда милли мәсьәләләрне дә читтән урап узмыйлар. 7-10 декабрь көнннәрендә **«Милли хәзинә» дип исемләнгән Идел буе уку йортларында укучы студентлар фестивале** узды. Биредә төрледән-төрле жанрлар, костюмнар, күл эшләре, искиткеч төрлелек, миллилек, яңа идеяләр, үзгәрешләр, югары зәвыклылык, нәфислекне күзәтеп булды.

2014 ел КФУ өчен гадәти генә ел түгел, чөнки быел яраткан университетыбыз **210 еллык юбилеен** каршылады. Туган көн тантанасы 6 декабрь көнне зурлап Татнефть-арена боз сараенда уздырылды. Әлеге гаҗәеп чарада КФУның 5 меңнән артык студенты, хезмәткәре һәм дәрәҗәле кунаклар катнашты.

Декабрьдә татар дөньясы өчен тагын бер күңелле вакыйга булды. 17 декабрьдә Мәскәүнең Муса Җәлил исемендәге 1186нчы этномәдәни татар компонентлы белем бирү мәктәбе базасында **Каюм Насыйри институты Белем бирү-мәдәни үзәге** ачылды. Аның кысаларында татар телен өйрәтү буенча бушлай курслар, Казан педагоглары лекцияләре, фәнни конференцияләр һ.б. оештырылачак. 19 декабрьдә исә, Казахстан Республикасы Астана шәһәрендә урнашкан Н.Л.Гумилев исемендәге Евразия милли университетында **Каюм Насыйри институтының чит илдәге беренче үзәге** ачылды.

Тагын бер күңелле яңалык: декабрь урталарында Мәскәүдә «Татар кызы – 2014» Бөтенроссия Матурлык конкурсы финалы узды. Идарә, икътисад һәм финанслар институтында инженер-эколог һөнәрен үзләштерүче студентыбыз Алинә Гыйззәтуллина җиңүче булды.

КФУ алга бара, үсә, яңаданяңа үрләр яулый. 2014нче ел уку йортыбыз өчен бик уңышлы узды. Киләсе еллар да аңа бары тик уңышлар гына алып килсен иде!

**Тормыш сукмаклары**

# Асыл затларда алтын туй!

Гомер итү – үргә менү, диләр. Ә үр менү бер дә җинел түгел, йә кояш пешерә, йә каршыдан искән җил-буран артка тартә. Менә шул чакта янында тормыш иптәшең – ышанычлы терәгең булу теләсә нинди авырлыкны да җиңәргә ярдәм итәчәк.

Шушы көннәрдә гомер итүләренең 50 еллык бәйрәмен – Алтын туйларын билгеләп үтүче хөрмәтле остазларыбыз Рауза Әмин кызы һәм Шәрипҗан Нурлыгәрәй улы Асылгәрәевләр тормышны бергәләп, кулга-кул тотынып үткән күркәм парлар.

Әлеге матур гаиләнең мәхәббәт тарихы 1960нчы елның августында, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керергә килгәч, Кызыл Позиция урамында урнашкан тулай торакта башлана. Уңышлы гына укырга кереп, һәр семестр саен зачет-имтиханнарын тапшырып, җәмәгать эшләрендә актив катнашып, биш елга якын вакыт сизелми дә узып китә. Студент елларында колхозларга барып, бер ай, ай ярым бәрәңге алып, борчак йолкып, мәк җыеп, концертлар куеп йөрүләр, уку еллары дәвамында оештырылган төрле чараларда катнашу аларны тагын да якынайта, бер-берсен аңларга, нинди кеше булуларын яхшырак чамаларга булыша.

5нче курста, 1964нче елның 26нчы декабрь шимбәсендә, иртәнге якта политэкономиядән имтихан биреп, көндезге сәгать 11дә ул вакыттагы Ленин урамында урнашкан Үзәк ЗАГСта язылышып, яшь Асылгәрәевләр гаиләсе барлыкка килә.

Университетны тәмамлагач, 1965нче елның июль ахырында, яшь гаиләне юллама буенча Биектау районы Ташлы Кавал авылының 8 еллык мәктәбенә җибәрәләр. Шәрипҗан әфәнде – директор, Рауза ханым рус теле укытучысы итеп билгеләнә. Авыл саен йөреп, 8нче сыйныфка укучылар туплап бетергәч (ул вакытта әле 8 еллык мәҗбүри уку кертелгән генә була), Шәрипҗан абыйны аспирантурага чакырып алалар. Рауза апа, эшен дәвам итеп, мәктәптә кала. 1966нчы елның февралендә ул, декрет ялына чыгып, Казанга кайта һәм 1966нчы елның 1нче мартында олы кызлары Айслу туа. Ике айлык декрет ялы беткәч, май аенда, Рауза апа кире мәктәбенә китә һәм июль беткәнче шунда эшли дә, яңадан ире янына Казанга кайта. Сентябрь-октябрь айларында вакытлы эштә эшләп торганнан соң, 1966нчы елның ноябрендә КДПИның татар теле белеме кафедрасында эшли башлый һәм шушы кафедрада лаборант, ассистент, өлкән укытучы, доцент вазифаларында 2013нче елның июленә кадәр хезмәт куя. 1976нчы елдан башлап, 2013нче елга кадәр Рауза апаның төп вазифаларыннан берсе – студентлар төркеменең академҗитәкчесе булу бер елга да өзелеп тормады: ул, 5әр ел җитәкләп, 7 төркем чыгарды. Һәр студенты белән бүген дә тыгыз бәйләнештә. Соңгы 8нче төркеме белән ике генә ел эшләп калса да, бәйләнешләре өзелми, аны һаман төркемнең җитәкчесе итеп санайлар, шатлык-борчулары белән уртаклашып торалар. 2011нче елда Рауза апа «КФУның иң яхшы академҗитәкчесе» исеменә лаек булды. Рауза Әминовна – ничә буын студентка төпле белем, яхшы тәрбия биргән остаз! Ул – минем дә хөрмәтле укытучым! Аның дәресләрен бүген дә сагынып искә алабыз, ул биргән белемнәрне эшебездә кулланабыз. Кайчан гына, нинди генә сорау-үтенеч белән мөрәҗәгать итмә, Рауза апабыз бер дә иренмичә ярдәмгә килә. Хәзерге көндә ул редакциябездә корректор вазифасын башкара. Газетада калган хаталарны төзәтеп кенә калмый, ә кагыйдәләрне яңадан исебезгә төшереп, киңәш бирүләрен дәвам итә.

Фәнни җәмәгатьчелеккә һәм мәктәп укытучыларына Рауза Асылгәрәева татар телен укыту методикасы буенча күп кенә фәнни мәкаләләр, программалар, методик ярдәмлекләр, татар һәм рус мәктәпләре укучылары өчен төзелгән татар теле дәреслекләре авторы буларак билгеле.

Шәрипҗан абый, КДУда аспирантура тәмамлап, 1968нче елда КДПИда кандидатлык диссертациясе яклый һәм шул институтның татар әдәбияты кафедрасына укытучы итеп билгеләнә. Ассистент, өлкән укытучы, доцент вазифаларын башкара, институтның партком секретаре урынбасары итеп сайлана. 1980нче елда Шәрипҗан абыйны партия өлкә комитетына эшкә алалар, 1982нче елда СССР Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтына фәнни эшләр буенча директор урынбасары итеп билгелиләр. Ул бүген дә шушы институтта эшли.

1969нчы елның 1 сентябрендә, гаиләгә ямь, бәхет өстәп, тагын бер кыз – Гөлшат туа. 1973нче елда аларга 3 бүлмәле фатир бирәләр, алар шунда бүгенгәчә яшиләр.





*Гаилә – ул җылы учак. Учак янына аның әгъзалары җыела. Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык та шулкадәр көчле була.*

Шактый озакка сузылган хезмәт юлында Асылгәрәевләр гаиләсе актив җәмәгать һәм фәнни-методик эшчәнлек алып бара, институт, республика, РСФСР, СССР дәрәҗәсендәге Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Алар икесе дә Татарстан Республикасының атказанган эшлеклеләре: Рауза Әмин кызы Татарстан мәктәпләренең атказанган укытучысы, Шәрипҗан Нурлыгәрәй улы – Татарстанның атказанган мәдәнияты хезмәткәре. Ул Почет билгесе ордены белән бүләкләнгән, аңа Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе Президентының һәм Татарстанның беренче Президенты М.Ш.Шәймиевнең Рәхмәт хатлары тапшырылган. Рауза апа да, Шәрипҗан абый да – хезмәт ветераннары һәм «Казанның 1000 еллыгы» медале белән бүләкләнгәннәр.

Бәхетне үлчәүгә салып үлчәп тә, сатып алып та булмый. Асылгәрәевләрнең бәхетенә күз тимәсен! Алар икесе дә өйдә – газиз әти-әни, эштә – ышанычлы хезмәттәш, дуслары өчен – яхшы сердәш, укучылары өчен – хөрмәтле остаз... Алма агачыннан ерак төшми, диләр. Ике кызлары да әти-әнисе юлыннан – фән юлыннан киттеләр. Икесе дә фәнни-тикшеренү институтында эшлиләр: олы кызлары – тарих фәннәре докторы, кечкенәсе – ветеринария фәннәр кандидаты. Шәрипҗан абый белән Рауза апа 3 онык өчен яраткан дәү әни белән дәү әти дә әле: Айратка 21 яшь, ул – КАИ студенты, Маратка 12 яшь, ул 6нчы сыйныфта укый. Кече оныклары Ринатка 5 яшь, ул балалар бакчасына йөри.

Алтын туйларына җиткән әлеге матур пар бүген дә, яшьлек ямен җуймыйча, бер-берсен яратып, хөрмәт итеп, үзләре биргән тәрбия җимешләрен татып, бәхетле тормыш кичереп яшиләр. Рауза апа белән Шәрипҗан абыйга әле шулай иңгә-иң куеп, тагын күп еллар яшәргә язсын!!!

**Динара Миннекаева**

**Мөхәррир сүзе**

Декабрь ае – еллык нәтиҗә ясау, үткәннәрне барлау, киләчәккә план-максатлар кору ае. Быелгы декабрьдә без газетабызның өч еллык эшчәнлегенә дә нәтиҗә ясыйбыз.

# Яшәсен иҗат!

Аллага шөкер, Россиядә генә түгел, ә бөтен илдә билгеле булган федераль дәрәҗәдәге уку йортында татар газетасы чыгып килү – татар студентлары өчен генә түгел, гомумән, татар халкы өчен зур бәхет. Моның өчен безгә һәрвакыт ярдәм кулы сузган җитәкчелеккә, укучыларыбыз, сезгә, иҗатташ дусларыбызга рәхмәт сүзләре җиткерәбез.

2011 елның 6 октябрендә тәүге тапкыр чыккан «Дарелфөнүн»ебезнең бүген 130нчы санын кулыгызда тотып торасыз. Шәхсән мин һәм минем укытучым, биткә салу һәм дизайн буенча белгеч Гөлфия Зилиф кызы Камалиева газетаның беренче көннәреннән бүгенгәчә аның сезнең тарафка килеп ирешүе өчен тырыштык. Барыбыз да яратып өлгергән хәбәрче Алинә Садыйкова мәкаләләре актуальлекләре, кызыклы булулары белән аерылып торалар. Остазыбыз Рауза Әмин кызы Асылгәрәева да редакциядә бик мөһим вазифа башкара. Ул язмаларда калган хаталарны төзәтә, без онытып җибәргән кагыйдәләрне искә төшерә. Шушы 3 ел дәвамында шактый гына үзгәрешләр дә булды: мөхәррирләр дә, хәбәрчеләр дә алышынды. Ничек кенә булмасын, аның уку йортыбызның тормышы белән таныштырып тору максаты калды, матур традицияләре дә барлыкка килде. Без даими рәвештә сезгә кызыклы булган сәхифәләр керттек, сезнең ярдәм белән яңаларын ачтык. Газета битләрендә үткәнгә кайттык, ата-бабаларабызның матур гореф-гадәтләрен искә төшердек, килеп туган проблемаларны бергәләп хәл итәргә тырыштык, татар халкының якты киләчәге турында уйлаштык, бер-беребез белән якыннан таныштык.

Газета ышанычлы укучылары булмаса яши алмый. Сезнең ышанычны тоеп эшләү безне яңадан-яңа үрләр яуларга этәрде. Беренче зур җиңүгә без 2012нче елда ирештек. ТРның «Ел студенты» студентлар премиясе бәйгесендә «Елның иң яхшы гаммәви матбугат чарасы» номинациясендә җиңеп чыктык. Икенчесе 2013нче елда Россиякүләм «Медиапокорение» фестивалендә «Иң яхшы корпоратив басма» номинациясендә I дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнү булды. Бу ел безгә тагын бер зур җиңү бүләк итте: XVII тапкыр узган «Бәллүр каләм» журналистлар конкурсында «ТРның корпоратив һәм махсуслашкан гаммәви матбугат чаралары» номинациясендә җиңүче булдык. Әлбәттә, һәр җиңү дә бик мөһим. Алар безнең уртак эш нәтиҗәсе. Редакциябезнең актив хәбәрчеләре Ләйсән Исхакова белән Илмир Вәлиев тә, редакциябез данын яклап, «КФУның ел студенты» бәйгесендә «Иң яхшы мәгълүмати чагылдыру» номинациясендә җиңү яулады.

Яңа ел яңа өметләр, күп кенә яңалыклар алып килә. 2015 ел да искәрмә булмас. Иң мөһиме, ул безгә сәламәтлек, тыныч һәм бәхетле тормыш, шатлык-куанычлар гына алып килсен иде. Редакциябезнең дә киләчәге үткәне һәм бүгенгесе кебек матур булыр дип ышанам. Сүз дә юк, аны ниндидер үзгәрешләр дә көтә. Аның составы да үзгәреш кичерәчәк. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул яшәргә, яраткан укучылары янәдан-яңа саннар белән сөендерергә, татар студентлары, татар халкы өчен хезмәт итәргә, уку йортыбыз студентларын берләштерә торган иҗат мәйданы булырга тиеш! Яңа ел – могҗизалар чоры да! Шуңа күрә без дә могҗизага ышанабыз!

Яшәсен иҗат! Яшәсен «Дарелфөнүн»!

**Ихтирам белән, барлык редакция хезмәткәрләре исеменнән, мөхәррир Динара Миннекаева.**

**Очрашу**

# Йога белән шөгыльләнгән әдип

**Алсу СӘЛАХОВА,**
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

23 декабрь көнне ТР Милли музеенда Нәкый Исәнбәтнең тууына 115 ел тулуга багышланган чара узды.

Кышкы рәхәт һава, Бауман урамындагы тарихилык, миллилек рухы бүгенге сәяхәтебезгә аерым бер төсмер бирде. Музейга килеп керүгә, бу хиска объектив аңлатма бирә алдым кебек: бүген нәрсәгә булса да фикерем үзгәрәчәк.

Кичәдә танылган татар зыялылары әдип турында истәлекләрен сөйләделәр. Ф.Галимуллин күренекле татар язучысы, шагыйрь, драматург, галим-филолог һәм фольклорчы, Г.Тукай ис. Дәүләт бүләге лауреаты һәм Татарстанның Халык язучысы Н.Исәнбәтнең хезмәтләреннән утыз томлык китап ясап булганлыгын искәртеп үтте. Нәкый аганың Хуҗа Насретдинын уйнаган Р.Шәрәфиев киләчәктә бөек әдибебез исемен йөрткән урам, тукталыш булдырылсын иде, дигән ихлас теләкләрен җиткерде. Л.Шакирҗан Нәкый абыйны бөтенләй башка яктан ачып шакаттырды: академия театры режиссеры П.Исәнбәтнең әтисе йога белән дә шөгыльләнгән икән!

Кичәне Н.Исәнбәтнең кызы – күп китаплар авторы, Россия һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Йолдыз Исәнбәт йомгаклады. Ул абыйларының һәм үзенең тормышында әтиләренең ролен (алар барысы да сәнгать өлкәсе кешеләре) сөйләп үтте. Кичәгә үзенең моңлы тавышы белән музыкаль ноктаны Р.Маликов куйды.

...Ниһаять, Н.Исәнбәт тормышына сәяхәт итүнең башында тойган серле хисләремә аңлатма таптым. Бүген тормышыма тагын бер кеше килеп керде! Нәкый абыйның минем күңелгә тәэсир итүе нәтиҗәсендә, милләтемә булган горурлык хисе тагын да артты.

• Яңа ел

# Кәҗә елы «кәҗәләнерме?»

**Тиздән, бик тиздән, Яңа ел житәчәк. Күпләр бу сихри кичне ничек, кем белән, нинди киемдә каршыларга, дип баш ватадыр. Чөнки елны ничек каршыласаң, аны шулай уздырырсың, дигән гыйбарә бар. 2015 ел – Көнчыгыш календаре буенча зәңгәр-яшел төстәге агач Кәҗә елы (япон мәдәнияте буенча Сарык елы). Киләсе елда безне ниләр көтә? Кәҗә елы кем өчен аеруча уңышлы булыр?**

Кәҗә әзергә-бәзер, китереп биргәнне көтеп, кул кушырып утырмаучыларга яхшы мөнәсәбәттә булачак. Эш урыннарын алыштыру, үз бизнесларын ачу яки карьера баскычыннан югарыга үрмәләү исәбенә аларның матди керемнәре артачак. Теләсә нинди хәлләргә оптимист күзлегеннән караучы һәм иҗади яктан үсәргә атлыгып торучыларга да Кәҗә күп табыш һәм уңыш китерәчәк. Якынлашып килүче елда андыйларга кызыклы тәкъдимнәр явачак һәм тормыш рәвешен тамырдан үзгәртү мөмкинлеге туачак.

Кәҗә – шук, яхшы күңелле, әмма бик үҗәт йорт хайваны. Димәк, кыенлыклардан курыкмаучыларны, кыю һәм куйган максатына ирешергә омтылучыларны яклаячак. Шуның белән бергә, Кәҗә уен-көлке, бәйрәм яратучан. Димәк, киләсе елда кәефне боза торган тормыш ваклыкларына игътибар итәргә һәм борын салындырып йөрергә һич кенә дә ярамый. Кешеләр белән бәхәс–низагтан ерак торучыларга карата да Кәҗә мәрхәмәтле булачак.

Шулай да артык грандиоз планнар корырга киңәш ителми. Ник дигәндә, кайвакыт киребеткән, үҗәт Кәҗә бар нәрсәнең астын өскә әйләндереп куярга мөмкин. Кәҗә ерак араларга күчеп йөрергә яратмый. Димәк, ерак сәяхәтләр бу ел өчен түгел. Иң яхшысы – инде булган урыннарга бару. Ә экзотик сәяхәтләрне киләчәккә калдыру яхшырак булыр.

Акча мәсьәләсендә тотрыклылык күзәтеләчәк. Әмма җиңел акча эшләү уен башка да кертергә ярамый. Тырышып, үҗәтләнеп эшләргә туры киләчәк. Шулай булмаганда, керемегезнең артуына өмет итә алмаячаксыз. Кәҗә елында ипотека рәсмиләштерү, кредит алу, зур суммада акча биреп тору яки бурычка алу кулай түгел.

Мәхәббәткә килгәндә, 2015 елда мавыгулар, флирт, романтика күп булачак. Җилбәзәгрәк Кәҗә игътибар үзәгендә булырга ярата. Әмма ялгышлык эшләп ташлый күрмәгез. Юкса язмышыгыз сезне читләтеп үтәчәк. Энергетика ягыннан көчле булмаган Кәҗә елында саулык турында кайгыртырга, чыныгырга, физик күнегүләр, зарядка ясарга, спорт белән актив шөгыльләнергә кирәк булачак.



## Ел хуҗасы – кәҗәгә ничек ярарга?

Яңа 2015 елны үз гаиләң белән, күңелле итеп каршыларга тырышырга кирәк, чөнки Кәҗә күңел ачуны ятарып кына калмый, үз гаиләсенә дә нык береккән. Яңа ел – гаилә бәйрәме. Иң якын кешеләрең белән очрашырга менә дигән сәбәп. Бу матур бәйрәмдә тулысы белән тормыш мәшәкатьләреннән арынырга, начар уй-фикерләрегезне башыгыздан чыгарырга кирәк.

Бәйрәмгә әзерләнгән вакытта, чисталыкка аеруча зур игътибар бирергә туры киләчәк. Кәҗә бит ул чисталык ярата торган йорт хайваны. Ул, тормыш сөючәнлеге, оптимизм хисенә ия булуы өстенә, мавыгучанлык, иркенлек ярата. Шуңа күрә бәйрәм якынлашканда театрга яки күргәзмәгә бару да ел хуҗасының күңеленә хуш киләчәк. Әмма Яңа ел төнендә үз гаиләң белән өйдә булу яхшырак булачак.

Өйне бизәгәндә, зәңгәр төснең һичшиксез булуы зарур. Шулай ук яшел һәм сары төсләрне дә кулланып, йортыгызны кышкы әкият иленә әйләндерегез.

Йорт бизәү бер хәл, бәйрәм өстәле турында да алдан ук уйлап куярга кирәк булачак. Яңа ел менюын төзегәндә, анда яшелчәләрнең күплегенә өстенлек бирегез.

Исегездә тотыгыз: Яңа елга ничек жентекле, иҗади әзерләнсәгез, елыгыз да шуның кадәр уңышлырак үтәр

## Ашаган күренми, кигән күренә яки Яңа елны нинди киемдә каршыларга?

Сихри Яңа ел төнен астрологлар нинди киемдә каршыларга киңәш итә соң? 2015 елны каршылаганда, кием өчен төп таләп – аның табигый тукымадан тегелгән булуы. Өс киеме затлы, зәвыклы булырга тиеш, бер генә төсле булса, тагын да яхшы. Зәңгәр, яшел, сары төсләргә өстенлек бирергә кирәк. Образны өстәмә аксессуарлар белән бизәргә, тулыландырырга була, тик аларның да табигый материаллардан булуы кулайрак. Кәҗә күп сандагы стразларга, йон, кәшимир, бәрхет, гомумән алганда, йомшак тукымаларга өстенлек бирә.

## 2015 ел хуҗасы нәрсә ярата? Бүләк сайлыйбыз!

Кәҗә яки Сарык йон әйберләрне яратырга тиеш, ди белгечләр. Мисал өчен, свитер, бияләй, оекбаш, юрган һәм башка шуның ише киң кулланыла торган әйберләр белән ел хуҗасының да, бүләк алучының да күңелен күрергә була.

Кәҗәнең тик тормавын исәпкә алып, бик якын кешеләреңә бүләк ителгән туристик юллама яки актив спорт, я булмаса бию түгәрәкләренә абонемент та ярап куярга тиеш (бигрәк тә бүләк алучыга!).

Бүләкләр сайлаганда, һичшиксез, ел хуҗасының нәзакәтле, матур хайван булуын да онытмаска кирәк. Шуңа күрә хатын-кызларга оригиналь бизәнү әйберләре, ир-атларга – балдак, сәгать, галстук кадагыч һәм башка шуның ише әйберләрне курыкмыйча алырга була. Тәмлетамакларга кыйммәтле кәҗә сыры бүләк итү дә ел хуҗасын юмалау булыр. Ел хуҗасы сувенирын сайлаганда да, агач материалга өстенлек бирегез. Андый бүләк алучыларга уңыш юлдаш булыр, ди астрологлар.

Бүләкне төрү материалын зәңгәр һәм яшел төсләрдән сайлагыз – ялгышмассыз! Ә менә якынлашучы елда хорафатларга ышанучылар кәҗә яки сарык тиресеннән эшләнгән әйберләрне бүләк итүне ел хуҗасын санламау белән тиңлиләр. Ни генә булмасын, бүләк алу һәм бүләк итү күңелле булсын өчен, аны чын йөрәктән башкарырга кирәк.

## Бәйрәм яме – уен белән

Бәйрәм табыны артында кунаклар моңсуланып утырмасын дисәгез, аларга кызыклы уеннар тәкъдим итәргә мөмкин. Сихри төн күңелле һәм мавыктыргыч узсын!

**Уйлап тап!**

Кәгазьне кисәкләргә бүлеп, кунакларга таратыгыз. Һәркем үзенең башкаларга таныш булмаган сыйфатларын язып чыксын. Аннары барысын да кәрзингә салыгыз һәм берәрләп тартып чыгарып укыгыз. Юллар авторын бергәләп уйлап табыгыз!

**Хикәя**

Кәгазь бите алыгыз, башыгызга килгән беренче җөмләне язып куегыз. Башкалар күрмәсен өчен, әлеге юлны бөкләп куегыз. Һәркем шул рәвешле берәр җөмлә язып чыксын. Иң мөһиме, кәгазьдәге юлларны каплап барырга кирәк - уенның кызыгы шунда! Иң соңгы булып фикерен өстәгән кеше кунаклар «бергәләп иҗат иткән хикәя»не кычкырып укый.

**Хәзинә**

Бергәләшеп түгәрәккә утырыгыз. Музыка башлангач, кулдан-кулга тартма җибәрегез. Алып баручы көйне туктатканда тартма кемдә калса, шул үзеннән берәр нәрсәне бирегә сала. «Кечкенә сандык» тулгач, кабат музыка җибәрелә. Хәзер инде көй туктаган арада тартма кемнең кулында кала, шул карамыйча кулына эләккән беренче хәзинәне алып үзенә кия.

**Кышкы моңнар**

Уен өчен алдан ук кәрзин, кышны чагылдырган сүзләр (чыршы, Кыш бабай, кар бөртеге, салкын, суык, буран, бозлы һ.б.) язылган кәгазьләр салына. Кунаклар чиратлап язуларны алып, андагы сүз кергән җыр башкарырга тиеш.

**www.almet-rt.ru сайты материаллары файдаланылды**

---

Язганыбызча, 2015 ел – Япон мәдәнияте буенча сарык елы. Шул уңайдан, Япониядән килеп, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында магистратурада белем алучы Юто Хишиямадан алардагы Яңа ел турында сораштык.



*«Яңа ел бәйрәме – Япониядә иң мөһим бәйрәм. Бәйрәм 1нче гыйнвардан 3нче гыйнварга кадәр 3 көн дәвам итә. Бу көннәрдә без барлык туганнар белән җыелып бәйрәм итәбез. Кибетләр һәм төрле компанияләр ябыла.*

*Бездә Яңа ел чыршысы 25нче декабрьгә кадәр генә тора, соңыннан алына. Кыш бабай бар, ләкин Кар кызы юк. Башта без, Яңа ел бәйрәмен чиста күңел белән каршы алу өчен, 31нче декабрьгә кадәр өйләрне җыештырабыз һәм «Ненгадзё» дип аталган яңа ел открыткасын язып, дусларыбыз, туганнарыбыз, танышларыбызга җибәребез. 31нче декабрьдә без «Тоси-коси соба» дигән озын токмачны (бу токмач кебек озын гомер теләп) ашыйбыз. «Тоси-коси» сүзенең мәгънәсе – иске елдан яңа елга күчү. Кичен күп кеше телевизордан «Кохаку ута гассэн» тапшыруын карый. Бу тапшыруда Япониядә иң популяр җырчылар, кызыл төркем һәм ак төркемгә бүленеп, җыр буенча ярышалар.*

*Буддизм гыйбадәтханәләренә баручылар да күп. Кичен Япониядәге бөтен Буддизм гыйбадәтханәләрендә 108 мәртәбә чаң кагыла. Бу чара «Дзёя но канэ» дип атала. Буддизм буенча, һәр кешенең 108 начар теләге бар, дип санала. Аларны юк итү өчен, чаң 108 мәртәбә кагыла.*

*Без Яңа ел бәйрәмендә, Синтоизм яки Буддизм гыйбадәтханәләренә барып, анда яңа ел безгә саулык, сәламәтлек, бәхет алып килүен телибез. Бу чара «Хацумодэ» дип атала.*

*Өй ишеге алдына «Кадомацу» дип аталган, нарат һәм бамбуктан ясалган бизәкне салабыз. Бу бизәк Яңа ел хуҗасын каршы алу өчен салына. Синтоизм буенча, яңа ел хуҗасы Яңа ел бәйрәмендә өйгә килеп, кешеләргә бәхет китерә, дип санала.*

*Балаларга әти-әниләре, әбибабайлары, туганнарыннан «Отосидама» дип аталган акча бүләк ителә. Акча кечкенә конверт эченә салына.*

*Яңа ел бәйрәмендә без кайбер махсус ризыклар ашыйбыз. «Осэти Рёри» – Яңа ел бәйрәмендә ашала торган традицион япон ризыклары җыелмасы. Өч кечкенә тартма эченә төрле ризыклар салына. Иң элек «Отосо» дип аталган татлы сакэ һәм «Озони» дигән аш ашыйбыз».*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.